# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

КАРАР

22 ноябрь 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылганнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертергә. Акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( Турай торак пунктына тирәннән су алу насосы сатып алу, Турай торак пунктындагы яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү өчен материал сатып алу, яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү)
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү ( Турай торак пунктында үлән чабу өчен триммер сатып алу; МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу)
3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Турай торак пунктында кышкы чорда юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү); юл өслеге өчен вак таш сатып алу ; транспорт хезмәтләре; МТЗ 82.1 тракторын карап тоту)
4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (1 ( бер ) данә янгын сүндерү гидрантларын сатып алу, Турай торак пунктының Крайняя урамында 1(бер) данә янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру.)
5) һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм

аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( Турай авылында махсус хәрби операциядә һәм Әфганстан сугышында катнашучыларга һәйкәлләр кую)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Турай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б.Куляшова